Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлегенең
Түбән Абдул авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

04 сентябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2023 елның 04 сентябрендә 15 сәгать 00 минутта, 2023 елның 04 сентябрендә 17 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә, түбәндәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Түбән Абдул авылында гражданнар җыенында кабул ителгән «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Түбән Абдул авылы җирлегендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2022 елның 19 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Түбән Абдул авылында гражданнарны су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, смет төзегән, техник күзәтчелек үткәргән, трактор сатып алган өчен түләү» өчен билгеләнгән гражданнарның керемнәре нигезендә сез 500 мең сум күләмендә үзара салым акчаларының калган өлешен түбәндәге җирле әһәмияттәге: «трактор өчен җиһазлар сатып алу?» мәсьәләсен хәл итүгә җибәрергә килешәсезме? соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 450 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 251 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 251 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлегенең Түбән Абдул авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Түбән Абдул авылында гражданнар җыенында кабул ителгән «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Түбән Абдул авылы җирлегендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2022 елның 19 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Түбән Абдул авылында гражданнарны су белән тәэмин итү системасын норматив хәлгә китерү, смет төзегән, техник күзәтчелек үткәргән, трактор сатып алган өчен түләү» өчен билгеләнгән гражданнарның керемнәре нигезендә сез 500 мең сум күләмендә үзара салым акчаларының калган өлешен түбәндәге җирле әһәмияттәге: «трактор өчен җиһазлар сатып алу?» мәсьәләсен хәл итүгә җибәрергә килешәсезме?” турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Түбән Абдул авылы, Ленин урамы, 92 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Абдул авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Абдул авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Юнысов